Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр детского творчества» Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан

**«Рассмотрено»**
На педагогическом совете МБУ ДО «ЦДТ»

Протокол № 1 от

«01» августа 2023 г.

**«Согласовано»**
Заместитель директора по учебно-воспитательной работе МБУ ДО «ЦДТ»
________/Л.М.Ибрагимова/

«01» августа 2023 г.

**«Утверждаю»**
Директор МБУ ДО «ЦДТ»
________/Р.Г. Иминова/

Приказ № 134 о\д от «01» сентября 2023 г.

# Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Родной край»

## Направление: Туристко-краеведческое

Возраст обучающихся: 11-15 лет
Срок реализации: 5 лет

Составитель: педагог дополнительного образования МБУ ДО «Центр детского творчества» Гарипова Г.Г.

2022 год

**Эчтәлек**

1. Аңлатма язуы
2. Максат
3. Бурычлар
4. Бүлекләр
5. Программаның эчтәлеге
   I. бүлек. Мин һәм минем гаиләм. (Тамгаларның тарихи әһәмияте. 16 сәгать).
   II. бүлек. Туган авылым – Биектауым (60 сәгать).
   III.бүлек. Авылым җирлегендә топонимнар (40 сәгать).
   1Vбүлек. Борынгы Чаллы шәһәрлеге (28 сәгать).
   V. Авылның күренекле шәхесләре (14 сәгать).
6. Программаның тематик бүленеше
7. Программаны тормышка ашыру юллары
8. Көтелгән нәтиҗәләр
9. Белем һәм күнекмәләрне бәяләү формалары
10. Куллану өчен әдәбият исемлеге
11. Өстәмә белем бирү программасының методик яктан тәэмин ителеше.
12. Куллану өчен әдәбият

**I бүлек.**

**Аңлатма язуы**

*Туган өен белмәгән,*
*Туган авылын белерме?*

*Туган авылын белмәгән,*
*Туган илен белерме?*
( Татар халык мәкале ).

Тормышыбызның

гомумкешелек кыйммәтләре булган гаделлек, намуслылык,шәфкатьлелек кебек асыл сыйфатлар юкка чыгып, кеше күңелен бары матди байлыкка омтылыш кына биләп алган бу заманда яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсендә яңа бурычлар килеп баса.

Һәр кеше үз төбәгенең үткәнен, табигатен, шунда яшәгән милләтләр тормышын, гореф – гадәтләрен, бәйрәмнәрен, туган телен өйрәнсә генә,халкыбызның киләчәге булыр. Туган җир. Туган туфрак, су һәм һава – кешене кеше итә торган кыйммәтле чынбарлык.

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз.Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш.Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала.

Туган якны яратырга өйрәтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү- патриотик тәрбия бирүнең беренче адымы. Патриотизм орлыклары гаиләдә үк салынырга тиеш. Кешенең нинди мохиттә тәрбияләнүе тормышта зур роль уйный. Укучыларны җанга рухи дәва бирүче туган як табигате, аның сихри көчкә ия булган чишмәләре, сабый чакта уйнап үскән хәтфә үләнле болыннары аша туган илебезне чын күңеленнән яратучы, милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр - Ватанның лаеклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләү патриотизм тәрбияләү өчен мөһим шарт булып тора. Бишек җырларыннан, ана теленнән башлап, балаларыбыз әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәне яратырга тиеш - әти-әнисен, дусларын, үзе уйнап үскән яшел чирәмле урамын, өен, кичке шәфәкъ балкышын, туган якларын калдырып киткән торна тавышларын, яңа чабылган үлән исен ...Чын йөрәге белән тоеп ярата белгән кеше генә туган иленең патриоты була ала.Үзенең кече Ватаны табигатенә рухы белән бәйләнгән кеше генә һәр агач, чәчәк, җәнлек, бөҗәк һәм һәр кеше язмышы өчен үзендә җаваплылык тояр.

Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк.Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең тарихын белергә, шуның аркылы халык тарихына якынаерга тиеш. Шәҗәрәләр төзү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала.

Музейга кергән һәр бала ветераннарга багышланган стенд, альбом, экспонатларны күрә,бигрәк тә кече яшьтәгеләр ныграк кызыксына, күп сораулар яудыралар.Алар моннан илебез азатлыгы өчен көрәшкән кешеләрнең исемнәре алдагы буыннарга җитәчәген аңлап чыга.

Музейда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр, туган якка кагылышлы җирле материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салына. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр - укучыларга чын-чынлап илһам чыганагы.Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү,тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек максатларга ирешү өчен музей материаллары - чиксез бай хәзинә.

Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота.Укучы үзе яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен аеруча яхшы белергә тиеш.

Тарихны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый.Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына, үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала.

**“ Туган як” түгәрәге түбәндәге максаттан чыгып оештырыла:**

-үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү;
-укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре формалаштыру;
-туган як белән кызыксынуларын үстерү һәм мәхәббәт тәрбияләү;
- туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:**

-укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;
-туган як тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү;
-укучыларда милли үзаң формалаштыру;
-тарихи урыннарга, табигатькә экскурсияләр үткәрү

**Шулардан чыгып түбәндәге бурычлар куела :**

- Укучыларның белемнәрен үстерү, китапка якынайту ;
- гомуми үсеш дәрәҗәләрен күтәрү

Өстәмә белем бирү буенча авторлык программа 5 - 11 нче класс укучылары өчен атнага 2 тапкыр 144 сәгатькә (бер елга), 5 уку елына төзелгән.

**Ул түбәндәге бүлекләрдән тора:**

“Туган авылым – Биектауым”

“Мин һәм минем гаиләм”( Тамгаларның тарихи әһәмияте).

“ Авылым җирлегендә топонимнар”

“Борынгы Чаллы шәһәрчеге”

“Авылыбызның күренекле шәхесләре”

Тәкьдим ителә торган 144 сәгатьлек авторлык программасы нигезендә күпьеллык укыту – тәрбия тәҗрибәсенә таянып, тел һәм әдәбият укытучыларына,сыйныф җитәкчеләренә,түгәрәк эшләрен оештыручыларга туган якны һәм аның талантлы кешеләре, якташ әдипләр, күренекле шәхесләр, төбәк тарихы,туган авылга тирән мәхәббәт,ихлас ярату тәрбияләү.

Һәр теманы өйрәнгәннән соң интеллектуаль уен, иҗади эш яки экскурсия планлаш-тырыла. Программаның актуальлеге – укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте,әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

## Программаның эчтәлеге

### I бүлек. Мин һәм минем гаиләм ( Тамгаларның тарихи әһәмияте) (16 сәгать).

Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрә турында аңлатма.Нәсел шәҗәрәләренең ерак тарихыбызны өйрәнү өчен мөһим чыганак булуы. Шәҗәрә төзү үрнәкләре.Нәселнең географиясе, нәсел башлыгын эзләп табу. Гаиләдә электән сакланган хатларны туплау, хатлардагы мәгълүматларны файдалану. Нәселнең шөгыльләрен, һөнәрләрен өйрәнү.Укымышлы һәм озын гомерле кешеләре турында мәгълүмат җыю. Гаилә традицияләре һәм аларны саклау. Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу -“Минем шәҗәрәм”. “Шәҗәрәдә - гаиләм тарихы”- дәрес-конференция. Нәсел агачын төзү үрнәкләре.

### II бүлек. Туган авылым - Биектауым. (60 сәгать)

Авылга нигез салыну. Исеме , риваятьләре, мәйданы, географик урыны, халкы, сулыклары, истәлекле урыннары, атамалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән танышу. Авыл кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләре. Бәет, җырлар чыгаручы кешеләр белән очрашу. Авыл һөнәрчеләре һәм һөнәрләре турында мәгълүмат җыю, кул эшләреннән күргәзмә әзерләү,видеотасмага төшерү. Колхоз һәм башка оешмаларның тарихы. Хезмәт кешеләренең тормышын өйрәнү, төрле һөнәр ияләре белән очрашулар үткәрү. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, өчпочмаклы солдат хатлары,сугыш чоры балалары

турында материаллар туплау, өйләрендә булу. Фәнни-тикшеренү эшләре башкару. Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар белән очрашу, алар турында стенд эшләү. Мәктәп , мәдрәсәләр тарихын өйрәнү, ветеран укытучылар , чыгарылыш укучылары белән очрашулар үткәрү, мәктәп тарихын язу күздә тотыла. Мәктәп музеена экскурсия. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын өйрәнү, кылган гамәлләрен хөрмәтләү, яшь буынны шулар үрнәгендә тәрбияләү. Истәлекле урыннарга сәяхәт.Чишмәләр,су буйларын күзәтү. Тарихи – экологик сукмак буйлап сәяхәт.

## III.Авылым җирлегендә топонимнар. (40 сәгать).

Ономастика фәне һәм аның тармаклары.Ономастиканың үсеш темплары һәм дөньякүләм әһәмияте. Авыл топонимикасы : урман,тау, болын исемнәрен ачыклау. Гидронимика. Авып тирәсендә урнашкан елга, күл, чишмәләрнең исемнәрен ачыклау. Биектау авылының килеп чыгышы. Авыл тарихы һәм кеше исемнәре белән бәйле риваятьләрне ачыклау.

## IV. Борынгы Чаллы шәһәрчеге тарихы. (28 сәгать).

Борынгы Чаллы төбәгендәге кабер ташлары. Чаллы шәһәрлегенең киләчәгенә бәйле вакыйгалар белән танышу. Идрис Зөлмөхәммәт Хафиз (Хәлфә) һәм аның нәселе. Котлы Бөкәш Чаллысы авылының килеп чыгышы. Котлы Бөкәш мәктәбе музеена экскурсия, андагы чыганаклар белән танышу. Чаллы төбәге тарихын өйрәнүче археолог – галимнәр (Ф.Хуҗин.,Н.Гариф. “Изге учак монда сүнмәсен”,”Без кемнәрнең оныклары”,”Тарихи сәхифәләр ачылганда”,”Борынгы Чаллы төбәге : документлар телендә сөйләшәбез”).

## V. Авылның күренекле шәхесләре. (14 сәгать ).

Күренекле шәхесләргә кагылышлы язмалар тупланмасын булдыру, алар белән элемтәдә булу.Зыялы шәхесләргә багышланган фото һәм видео – альбомнар эшләү, экскусоводлар әзерләү. Мәктәп музеена экспонатлар туплау максатыннан өйләргә йөрү, төрле шәхесләр белән очрашу. Авылыбыздан чыккан күренекле шәхесләр белән очрашу кичәсе уздыру.

## Программаның тематик бүленеше

| № | Тема | Сәгать саны | Тео-ретик | Практик |
|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек** | Мин һәм минем гаиләм. Тамгаларның тарихи әһәмияте. | 16 | 2 | 14 |
| 1 | “Әдәби туган як” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре.<br><br>Үз нәселеңне беләсеңме?-гаилә тарихын өйрәнү (Әңгәмә, эзләнү) | 2 | 1 | 1 |
| 2 | Хатлар ни сөйли? (Эзләнүэше) | 2 | 0 | 2 |
| 3 | Нәселем шәҗәрәсе | 2 | 1 | 1 |
| 4 | Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре (Эзләнү эше) | 2 | 0 | 2 |
| 5 | Нәселем традицияләре (Язма эш) | 2 | 0 | 2 |
| 6 | Һәр буынга сыйфатлама-характеристика язу | 2 | 0 | 2 |
| 7 | “Шәҗәрәдә гаиләм тарихы” (Дәрес-конференция) | 2 | 0 | 2 |
| 8 | Нәсел агачын төзү үрнәкләре | 2 | 0 | 2 |
| **2 нче бүлек** | Туган авылым–Биектау | 60 | 9 | 51 |
| 1 | Авылым тарихы | 2 | 2 | 0 |
| 2 | Авылымның исеме каян килеп чыккан? (Эзләнү эше) | 2 | 0 | 2 |
| 3 | Авылымдагы географика тамалар һәм аларның тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу) | 3 | 1 | 2 |
| 4 | Авылым кешеләренең культурасы һәм көнкүреше(җырлар,<br><br>бәетләр). Видеотасмага төшерү. | 2 | 0 | 2 |
| 5 | Авылым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре .Мәктәп музеена экскурсия | 1 | 0 | 1 |
| 6 | Колхоз тарихы .<br><br>Мәктәп музеена экскурсия | 2 | 1 | 1 |
| 7 | Авылдагы хезмәт һәм хезмәткешеләре ( Төрле һөнәр ияләре белән очрашу). | 2 | 1 | 1 |
| 8 | Авылым кешеләре Бөек Ватан сугышында (Ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу һәм өчпочмаклы солдат хатларын туплау). | 2 | 1 | 1 |
| 9 | Сугыш чоры балалары (Эзләнү эше,очрашулар) | 8 | 3 | 5 |
| 10 | АларВатан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар белән очрашу,стенд төзү) | 2 | 0 | 2 |
| 11 | Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | 2 | 1 | 1 |
| 12 | Мәктәпнең элеке укытучылары ( Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллартуплау) | 1 | 0 | 1 |
| 13 | Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) | 2 | 0 | 2 |
| 14 | Алар безнең мәктәптә укыдылар (Материаллар туплау, стенд төзү) | 2 | 0 | 2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | Шушы яктан, шушы туфрактан без.<br><br>Күренекле авылдашлар белән очрашуүткәрү. | 2 | 0 | 2 |
| 16<br><br>17<br><br>18<br><br>19<br><br>20 | “Якты йолдыз булып яна<br><br>Биектау күңелемдә”<br><br>Дәрес- конференция<br><br>Авылымның тарихи урыннары. Чишмәләр, су буйларын күзәтү. Экскурсия. | 2 | 0 | 2 |
| | | 1 | 0 | 1 |
| | Тарихи – экологик сукмак буйлап читтән торып сәяхәт | 1 | 1 | 0 |
| | Тарихи – буйлап экскурсия:<br><br>-“Мәктәп тукталышы”<br><br>Катмыш урманы | 2 | 1 | 1 |
| | Эзләнү – тикшеренү эшләре | 5 | 1 | 4 |
| | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 3 | 1 | 2 |
| **3 нче бүлек** | Авылым җирлегендә топонимнар. | 40 | 12 | 28 |
| | Ономастика фәне һәм аның тармаклары. | 5 | 2 | 2 |
| | Ономастиканың үсеш темплары һәм дөньякүләм әһәмияте<br><br>Авыл топонимикасы : урман, тау,болын исемнәрен ачыклау.<br><br>Гидронимика. Авыл тирәсендә урнашкан елга, күл, чишмәләрнең исемен ачыклау.<br><br>Биектау авылының килеп чыгышын өйрәнү.<br><br>Авыл тарихы һәм кеше исемнәре белән бәйле риваятьләрне ачыклау. | 9<br><br>10<br><br>5<br><br>8 | 2 | 4<br><br>4<br><br>4<br><br>4<br><br>3 |
| **4 нчебүлек.** | Борынгы Чаллы шәһәрчеге тарихы | 28 | 10 | 18 |
| 1 | Борынгы Чаллы төбәгендәге кабер ташлары | 3 | 2 | 4 |
| 2 | Чаллы шәһәрлегенең киләчәгенә бәйле вакыйгалар белән танышу | 10 | 2 | 5 |
| 3 | Идрис Зөлмөхәммәт Хафиз (Хәлфә) һәм аның нәселе | 5 | 2 | 3 |
| 4 | Котлы Бөкәш Чаллысы авылының килеп чыгышы. Котлы Бөкәш музеена экскурсия, андагы чыганаклар белән танышу | 4<br><br>2 | 2 | 2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **5** | Чаллы төбәге тарихын өйрәнүче археолог – галимнәр белән очрашу. ( Ф.Хуҗин., Н.Гариф. “Без кемнәрнең оныклары”.,Тарихи сәхифәләр ачылганда”.,”Борынгы Чаллы төбәге : документлар турында сөйлибез”). | 4 | 2 | 4 |
| **5 нче бүлек** | Авылымның күренекле шәхесләре. (14 сәгать). | | | |
| | Күренекле шәхесләргә кагылышлы язмалар тупланмасын булдыру, алар белән элемтәдә тору. | 4 | 2 | 2 |
| 1 | Зыялы шәхесләргә багышланган фото һәм видео – альбомнар ясау, экскурсоводлар әзерләү. | 6 | 2 | 4 |
| 2 | Мәктәп музеена экспонатлар туплау максатыннан өйләргә йөрү, төрле шәхесләр белән очрашу. | 2 | 2 | 0 |
| 3 | Авылымнан чыккан күренекле шәхесләр белән очрашу кичәсе уздыру. | 2 | 0 | 2 |
| 4 | | 144 | 44 | 100 |

## Программаны тормышка ашыру юллары.

Түгәрәктә туган як әдәбияты һәм тарихы белән кызыксынган балалар шөгыльләнә. Программа үткәннән алып бүгенгесенә кадәр үз эченә ала.Туган як тарихын өйрәнү юллары һәм методлары төрле : семинар, экскурсия, очрашулар, төрле уеннар, эзләнү –тикшеренү эшләре һ.б. Аларны үткәрү укучының яшеннән, әзерлек дәрәҗәсеннән, түгәрәк занятиеләренең максатыннан тора.Бигрәктә экскурсияләр укучыларда зур кызыксыну уята. Укучыларның түгәрәк белән кызыксынулары артсын өчен, укытучы үткәрү формаларын чиратлаштырып барырга тиеш. Балалар мөстәкыйль рәвештә документаль чыганакларны өйрәнеп, тикшеренү эшләре алып барырга омтылалар. Тикшеренү эшләре укытучы җитәкчелегендә алып барыла. Эшне оештырган укытучы үзе дә, беренчедән, төбәк тарихы буенча төп чыганакларны белергә тиеш. Икенчедән, үзе дә тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, укучының эше белән кызыксынырга ,өченчедән, туган як әдәбиятын, тарихын өйрәнү буенча класстан тыш эшләрдә оештыручы булырга тиеш.

Укучыларны бигрәк тә үзләренең күңелләренә якын булган, танышлары, якыннары катнашкан вакыйгалар, авылның барлыкка килүе кызыксындыра. Шуңа да тарих, әдәбият дәресләрендә тарихи вакыйга турында сөйләгәндә ,бу вакыйганың безнең җирлеккә, авыл кешеләренә нинди мөнәсәбәте булуын аңлату кирәк.

Бу авторлык прогаммасы укучыларга туган төбәкнең тарихы ,мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында тирәнрәк аңларга, төрле формадагы эзләнү эшләренә–гади язмадан башлап, фәнни-тикшеренү эшләренә кадәр–өйрәнергә мөмкинлек бирә .Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре укучылар тарафыннан иҗади эшләр, реферат, фәнни-тикшерен эшләре, презентацияләр һ.б. формасында тәкъдим ителә.

## Көтелгән нәтиҗәләр:

“ Туган якны” өйрәнү түгәрәгендә шөгыльләнгән бала:
-үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
-мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый,
-материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;
-эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
-туган як әдәбияты, тарихы буенча белемнәрен арттыра;
-фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;
- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле күренекле шәхесләре белән горурлану.

## Белем һәм күнекмәләрне бәяләү формалары.

| № | Темалар | Белем һәм күнекмәләр | Контроль төре |
|---|---|---|---|
| 1. | “Мин<br><br>һәм минем гаиләм” | Үзләренең нәсел тамырлары, үз , гаилә ләренең тарихын белү. Гаилә традицияләре һәм аларны саклау.<br><br>Нәсел агачын төзү . | “Шәҗәрәдә – гаиләмтарихы”-дәрес-конференция.<br><br>Нәсел агачын төзүгә конкурс. |
| 2. | “Туган авылым - Биектау” | Авылның исеме, риваятьләре, мәйданы, географик урыны, халкы, сулыклары, истәлекле урыннары, атамалары, хайваннарһәм үсемлекләр дөньясы; авыл кешеләренең культурасы, гореф-гадәтләрен; Бөек Ватан сугышы елларында безнең авылдашлар, Әфганстанда хәрби хезмәттә булучылар турында белү. Төбәгебездәге күренекле кешеләрнең тормышларын белеп, аларның кылган гамәлләрен хөрмәтләү, үзләрен шулар үрнәгендә тәрбияләү . | Викторина “Биектау авылыңны беләсеңме?”<br><br>Проект яклау “Тарихи – экологик сукмак буйлап...” |
| 3. | “Авылым җирлегендә топонимнар | Ономастика фәне һәм аның килеп чыгышы, аның тармакларын өйрәнү, урман. тау, болыннарның исемнәрен ачыклау. Авыл тирәсендә елга, күл, чишмәләрнең исемнәрен белү. Биектау авылының килеп чыгышын өйрәнү, кеше исемнәре белән бәйле риваятьләрне ачыклау | Рефератлар.<br><br>Сочинение һәм шигырьләр язуга конкурс. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 нчебүлек. | Борынгы Чаллы шәһәрчеге тарихы | 28 | 10 | 18 |
| 1 | Борынгы Чаллы төбәгендәге кабер ташлары | 3 | 2 | 4 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Чаллы шәһәрлегенең киләчәгенә бәйле вакыйгалар белән танышу | 10 | 2 | 5 |
| 3 | Идрис Зөлмөхәммәт Хафиз (Хәлфә) һәм аның нәселе | 5 | 2 | 3 |
| 4 | Котлы Бөкәш Чаллысы авылының килеп чыгышы. Котлы Бөкәш музеена экскурсия, андагы чыганаклар белән танышу | 4<br>2 | 2 | 2 |
| 5<br><br>5 нче бүлек<br><br>1<br><br>2<br><br>3 | Чаллы төбәге тарихын өйрәнүче археолог – галимнәр белән очрашу. ( Ф.Хуҗин., Н.Гариф. “Без кемнәрнең оныклары”.,Тарихи сәхифәләр ачылганда”.,”Борынгы Чаллы төбәге : документлар турында сөйлибез”).<br><br>Авылымның күренекле шәхесләре. (14 сәгать).<br><br>Күренекле шәхесләргә кагылышлы язмалар тупланмасын булдыру, алар белән элемтәдә тору.<br><br>Зыялы шәхесләргә багышланган фото һәм видео – альбомнар ясау, экскурсоводлар әзерләү.<br><br>Мәктәп музеена экспонатлар туплау максатыннан өйләргә йөрү, төрле шәхесләр белән очрашу.<br><br>Авылымнан чыккан күренекле шәхесләр белән очрашу кичәсе уздыру. | 4<br><br>4<br><br>6<br><br>2<br><br>2 | 2<br><br>2<br><br>2<br><br>2<br><br>0 | 4<br><br>2<br><br>4<br><br>0<br><br>2 |
| 4 | | | | |

**Куллану өчен әдәбият исемлеге:**

1. Гарипова Г.Х. – “Телен белгән – ил ачар” Казан: “Гыйлем” нәшрияты, 2011 ел. – 4-9 б.

2. Н.Гариф.”Без кемнең оныклары”.,Тарихи сәхифәләр ачылганда”2008 ел.

3.Н.Гариф.Борынгы Чаллы шәһәрчеге.Тарих институты басмаханәсе, Казан.2008 ел.

4. Книга памяти о советских воинах, погибших в Афганистане.-т-2, Москва, Военное издательство, 1999

5. Музей материаллары. Ачык дәрес материаллары.

**Өстәмә белем бирү программасының методик яктан тәэмин ителеше.**

1. 2004 - 2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы //Мәгариф. – 2005. - №1. – Б. 38.

2. Татар мәктәпләрендә татар балаларына татар теле һәм әдәбияты укыту программалары. – Мәгариф, 2010.

3. “Мәгариф”журналлары

4. Краеведческая программа. “Литературное краеведение”, составлена С.С.Кулаковой.

5. Интернет-ресурслар: “Открытый класс”, “Белем ru.” Һ.б сайтлар.

6.”Ачык дәрес” методик кулланма.2011,2012,2013,2014.